| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**<br>**2016 елның 21 апреле** | Зеленодольск шәһәре | **КАРАР**<br>**№ 1045** |

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2014 елның 07 октябрендәге 1978 нче номерлы карары белән расланган 2015-2017 елларга Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районында террорчылыкны һәм экстремистлыкны профилактикалау муниципаль программасына үзгәрешләр кертү турында

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” Федераль законның 15 статьясындагы 6.1 өлеше, 2006 елның 6 мартындагы 35-ФЗ номерлы “Террорчылыкка каршы тору турында”, 2002 елның 25 июлендәге 114-ФЗ номерлы “Экстремистик эшчәнлеккә каршы тору турында” Федераль законнары, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Уставы нигезендә һәм Россия Федерациясе Президенты 2013 елның 26 апрелендә расланган 2013-2018 елларга Россия Федерациясендә террорчылык идеологиясенә каршы торуның комплекслы планын үтәү буенча террорчылыкка каршы милли комитет тәкъдимнәрен исәпкә алып, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. 2014 елның 07 октябрендәге 1978 номерлы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән расланган 2015-2017 елларга Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районында террорчылыкны һәм экстремистлыкны профилактикалау муниципаль программасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

-VI таблица. «Программа чаралары»на 11 бүлек өстәргә һәм аны кушымта нигезендә бәян итәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) Интернет челтәрендә урнаштырырга.

3  Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары А.В.Старостинга йөкләргә.

Җитәкче А.Х. Сәхибуллин

**Кушымта**

| №№ тб | Чараның атамасы | Башкаручылар | Финанслау күләме (мең сум) | шул исәптән | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2015 ел | 2016 ел | 2017 ел |
| **11. Россия Федерациясе Президенты 2013 елның 26 апрелендә расланган 2013 - 2018 елларга Россия Федерациясендә террорчылык идеологиясенә каршы тору комплексы планы чаралары** | | | | | | |
| 53 | Террорчылык идеологиясе йогынтысына дучар ителгән яки инде эләккән затларга (яшьләр; дини, нигездә ислам, чит илдә белем алган затлар; террорчылык (экстремистлык) эшчәнлеге өчен җәза алган җинаятьчеләр, бандподполь әгъзаларының туганнары) адреслы профилактик йогынты ясау буенча «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә даими эшләүче квалификацияле белгечләр (коллективлар) сайлап алуны оештырырга. | ЗМРда ТКК (АТК) РФ ТР ФИХБ, ЗР ЭЭМ бүлеге | * | | | |
| 54 | Террорчылыкка каршы эчтәлекле мәгълүматны, шул исәптән видеороликларны, социаль челтәрләрдә һәм Интернет челтәренең район мәгълүмат ресурсларында блогларда әзерләүне һәм урнаштыруны тәэмин итәргә | ЗМРда ТКК (АТК) | * | | | |
| 55 | Террорчылыкка һәм экстремистлыкка каршы юнәлештәге документаль һәм сәнгать фильмнары (шул исәптән видеофильмнар) таратуда кинопрокат системасын җәлеп итәргә | ЗМР Башкарма комитетының мәдәният идарәсе | * | | | |
| 56 | Милләтара мөнәсәбәтләрне камилләштерүгә юнәлдерелгән мәдәни-агарту чараларын оештырырга һәм уздырырга | ЗМР ММИ (ОМС), ЗМР БК Мәдәният идарәсе, ЗМР БК мәгариф идарәсе | * | | | |
| 57 | Даими рәвештә кинофильмнар күрсәтергә, халык иҗаты коллективлары чыгышларын оештырырга, спектакльләр күрсәтергә, күргәзмәләр, түгәрәк өстәлләр, семинарлар үткәрергә, «Террорчылыкка каршы торуның мөһим факты буларак халыкара хезмәттәшлекне ныгыту» темасына | ЗМР ММИ (ОМС), ЗМР БК Мәдәният идарәсе, ЗМР БК мәгариф идарәсе | * | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | багышланган кинофильмнар күрсәтергә, семинарлар оештырырга. | | | | | |
| 58 | Яшьләрне рухи һәм патриотик тәрбияләүгә юнәлтелгән халык иҗаты өлкәсендә чаралар оештырырга һәм уздырырга | ЗМР Башкарма комитетының мәдәният идарәсе | * | | | |
| 59 | Террорчылыкка каршы тору өлкәсендә җәмәгатьчелек фикерен өйрәнү өчен социологик тикшеренүләр уздыруны оештырырга. | ЗМРда ТКК (АТК) | * | | | |
| 60 | Патриотик рухта һәм физик яктан алга киткән яшь буынны тәрбияләүгә юнәлдерелгән, тормыш уңышының нигезе һәм террорчылык  һәм экстремизмны профилактикалауның мөһим алшарты буларак, шәхси иҗади хезмәткә юнәлдерелгән чараларны күздә тоткан чаралар  планнар һәм программаларга төзәтмәләр кертергә (гамәлдәге төзәтмәләр кертергә) | БК Мәдәният идарәсе, ЗМР БК мәгариф идарәсе, ЗМР БК яшьләр эшләре һәм спорт идарәсе | * | | | |
| 61 | Яшьләргә гражданлык-патриотик һәм рухи-әхлакый тәрбия бирү өлкәсендә эш алып баручы яшьләр берләшмәләре эшчәнлеген мониторинглауны тормышка ашырырга | Яшьләр эшләре һәм спорт буенча ЗМР БК идарәсе | * | | | |
| 62 | Террорчылык һәм экстремистик юнәлешле җинаятьләр өчен җәза алган гражданнарны социаль реабилитацияләү чараларын гамәлгә ашырырга | ЗМРда ТКК (АТК) РФ ТР  ФИХБ, ЗР ЭЭМ бүлеге | * | | | |